ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.11.2024 ел Баулы шәһәре №176

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 августындагы 172 номерлы «Баулы муниципаль районы территориясендә халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары төзү» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм зыяннарны, табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү Министрлыгының 2024 елның 12 сентябрендәге М-11-3271 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 августындагы 172 номерлы «Баулы муниципаль районы территориясендә халыкны вакытлыча урнаштыру пунктлары төзү» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның бөтен тексты буенча «халыкны вакытлыча урнаштыру пункты» сүзләрен, «вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пункты» сүзләренә тиешле килештә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.Л. Бакиров